КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 19 сентябрь г.Казань № 1162

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Советлар Союзы Герое, Россия Федерациясе Герое, Социалистик Хезмәт Герое, Россия Федерациясе Хезмәт Герое исемнәре бирелгән, Дан орденының тулы кавалерлары булган, өч дәрәҗәдәге Хезмәт Даны ордены белән бүләкләнгән гражданнарга «Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары һәм Дан орденының тулы кавалерлары статусы турында» 1993 елның 15 гыйнварындагы 4301-1 номерлы Россия Федерациясе законында, «Социалистик Хезмәт Геройларына, Россия Федерациясе Хезмәт геройларына һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына социаль гарантияләр бирү турында» 1997 елның 9 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законда каралган ташламалар бирүгә бәйле чыгымнарны финанслау тәртибен раслау турында» 2005 ел, 24 март, 146 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Советлар Союзы Герое, Россия Федерациясе Герое, Социалистик Хезмәт Герое, Россия Федерациясе Хезмәт Герое исемнәре бирелгән, Дан орденының тулы кавалерлары булган, өч дәрәҗәдәге Хезмәт Даны ордены белән бүләкләнгән гражданнарга «Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары һәм Дан орденының тулы кавалерлары статусы

турында» 1993 елның 15 гыйнварындагы 4301-1 номерлы Россия Федерациясе законында, «Социалистик Хезмәт Геройларына, Россия Федерациясе Хезмәт геройларына һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына социаль гарантияләр бирү турында» 1997 елның 9 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законда каралган ташламалар бирүгә бәйле чыгымнарны финанслау тәртибен раслау турында» 2005 ел, 24 март, 146 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 13 июнь, 301 нче; 2007 ел, 29 апрель, 167 нче; 2007 ел, 16 май, 188 нче; 2007 ел, 6 декабрь, 697 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 2 сентябрь, 634 нче, 2023 ел, 03 апрель, 391 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның өченче абзацында «министрлыклар һәм ведомстволар» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «министрлыклар һәм ведомстволар» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Советлар Союзы Герое, Россия Федерациясе Герое, Социалистик Хезмәт Герое, Россия Федерациясе Хезмәт Герое исемнәре бирелгән, Дан орденының тулы кавалерлары булган, өч дәрәҗәдәге Хезмәт Даны ордены белән бүләкләнгән гражданнарга «Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары һәм Дан орденының тулы кавалерлары статусы турында» 1993 елның 15 гыйнварындагы 4301-1 номерлы Россия Федерациясе законында, «Социалистик Хезмәт Геройларына, Россия Федерациясе Хезмәт геройларына һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына социаль гарантияләр бирү турында» 1997 елның 9 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законда  каралган ташламалар бирүгә бәйле чыгымнарны финанслау тәртибенең 12 пунктында «министрлыклар һәм ведомстволар» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин